Әнвәр ШӘРИПОВ

# Кем идем мин?..


## Туган авылым Кәрәкәшледә. 1943 ел

Сугыш чоры. Мин әле бәләкәй, берни белми торган бала икәнмен. Елап ятам икән; елыйм да елыйм икән. Шул чакта кемнеңдер: «И-и, еламасана инде... Менә әрчеп бетерәм. Пешеп чыксын да, ашарсың», – дигән сүзләрен ишетәм. Мин күземне ачтым һәм кинәт шул чакта миңа аң керде. Мин сәкедә ятам икән, ә минем янымда берәү (соңыннан мин аның Дания апа икәнен белдем) вак кына бәрәңге әрчеп утыра. Мичтә ут яна, казанда су кайный. Минем бик ашыйсым килә икән, шуңа елыйм икән. Мин кулым белән күземне сөрттем һәм аңлап алдым: миңа бераз еламый торырга, бәрәңге пешеп чыкканын көтәргә кирәк икән бит. Сабыр итәргә, ашыйсым килсә дә, түзәргә кирәк икән... Елаудан файда юк икән. Һәм мин әкренләп елаудан туктадым. Бераз вакыт үтте, һәм апам, казаннан пешкән вак бәрәңгеләр алып, мине ашата башлады...

Шул көннән соң мин әкренләп үзебезнең тормышны да аңлый башладым. Безнең гаиләдә иң өлкән, иң олы кеше – ул әни икән. Ләкин мин аны бик аз гына күреп калам: ул кич белән генә кайта да, иртән иртүк, мин торганчы ук, колхоз эшенә китеп бара. Икенче зур кешебез – Кәүсәр абыем да гел колхоз эшендә. Көндез өйдә без өчебез генә: мин, Дания апа да миннән бераз гына зуррак Вәҗһия апа. Өйдәге бөтен эшне шул ике апа алып бара икән. Бездә башка кеше юк. Әти сугышка киткән; мин аның турында бары апамнар, әнинең сөйләве буенча гына беләм. Аңардан «хәбәрсез югалды» дигән хәбәр килгән.

Мине бармакларны бөгә-бөгә санарга өйрәттеләр: баш бармак – әни, имән бармак – Кәүсәр абый, урта бармак – Дания апа, атсыз бармак – Вәҗһия апа, чәнти бармак – мин үзем. Кулда – биш кенә бармак, һәрберсенең иясе бар. Анда әтигә урын юк; ул үзе дә юк бит. Әгәр үзе булса, бәлки, әни урынына әтине, ә Кәүсәр абый урынына әнине куяр идем дә, бишенче бармак Вәҗһия апа булып, мин үзем төшеп тә калыр идем. Ләкин әлегә мин апалар өйрәткәнчә, бармакларны шулай бөкли-бөкли, әтисез генә бишкә кадәр санап ятам.

Безнең бөтен карап торган кешебез – әни. Ул безгә әни дә, әти дә. Ул безне, әти юклыктан ятим итеп той-



**Әнвәр Мәгъдәнур улы ШӘРИПОВ** – *әдәбият тарихы галиме, педагог, публицист, язучы. 1941 елның 9 октябрендә Татарстанның элекке Ютазы (хәзерге Баулы) районы Кәрәкәшле авылында туа. Лениногорск районының Зәй-Каратай мәктәбен тәмамлый. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. 1971–1978 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшли. 1978 елның ноябреннән Алабуга педагогия институтына эшкә күчә, институтта әдәби иҗат түгәрәге оештыра. 1990 елда Чаллы педагогия институты ачылгач, шунда укыта башлый. 2001 елда «Борынгы төрки һәм урта гасырлар төрки-татар әдәбиятында шигъри жанрлар системасы» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. «КамАЗ төзелеше ударнигы» (1988), Россиянең халык мәгарифе отличнигы (1992), Татарстан Республикасының атказанган укытучысы (2005). Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (2001). Яр Чаллыда яши.*

дырмас өчен, үзенең бөтен көчен, тырышлыгын биреп яши. Ул безне ашата да, киендерә дә, бүген-иртәгә нәрсә эшләргә кирәклеген аңлатып, киңәшләр дә бирә.

Минем бөтен дөньям әлегә бары өй эче белән генә чикләнә. Кыш көннәрендә мин өйдә берүзем калам. Өйдәгеләр барысы да иртән кайсы-кая чыгып китәләр: әни – колхоз эшенә, Кәүсәр абый, Дания һәм Вәҗһия апалар – мәктәпкә. Берүзем калгач, мин башта бераз уенчыгым белән уйнап утырам. Уенчык дигәнем – каяндыр табып алынган бер озынча кечкенә тимер кисәге; аның бер башында мич торбасы кебек эче тишек торбасы бар. Мин аны паровоз итеп уйныйм. Паровоз тавышлары чыгарам: «Што-што, пу-уп! Што-што, пу-уп!» Минем бит чын паровозны да күргәнем бар: безнең авылдан ерак түгел, калкулык өстеннән көн саен, чыж-чыж парлар чыгарып, шундый паровоз узып тора. Мин аны беренче тапкыр кайчан күргәнмендер, анысын хәтерләмим, әмма чыннан да күргәнем бар.

Шулай уйнап утырам да, аннан тәрәзәгә барып, карланып беткән пыялага өреп, аны бармагым белән җылытып, «күз» ясыйм, шуннан урамнан үткән-сүткән кешеләрне карап утырам. Берүзем чакта үземнең шулай карап утыруымны әйткәч, әни миңа: «Маңгаеңны тәрәзәгә терәмә. Салкын тидерерсең», – диде. Мин шулай карап утыра-утыра, күрше-тирә кешеләрнең кайчан кая барганын белеп торам яки аларның кая барганын үзем уйлап чыгарам. Безнең урамнан көн саен диярлек безгә туган тиешле Фазыйла абыстай (минем әтинең апасы) үтеп киткәли. Кайчан карама, ул һәрвакыт башын кырын салып барган

булыр. Шуңа мин аны «Кыек» дип атадым. Бер көнне ул әни өйдә чакта турыбыздан узып китте. Мин әнигә: «Әнә, кара, Тыек бара», – дидем. Әни башта аңламый торды да, аннан: «Ә, кыек дип әйтәсең. Син аңардан көлмә, улым, – диде. – Ул бу авыр тормышта, ничек балаларыма ашарга житкерим икән, дип уйланып, «ишеп-сүтеп» йөри. Бер үзенә өч бала бит. Ире сугышта. Килер жире юк. Берүзе колхозда эшли», – диде. Шуннан соң мин аңладым, әйе шул, ишектән чыгуыңа сине ачлык, фәкыйрьлек сагалап тора.

Безнең йорт Ютазы елгасы ярында, елгадан ерак түгел, бер йорт аша гына иде. Ә бераз арырак киткәч, елга ярында, тимерчелек алачыгы бар. Жәй көннәрендә без, балалар, шул алачык янында уйнарга ярата идек. Тәмам караңгы төшеп беткәнче качышлы һәм башка уеннар уйный идек. Кәрәкәшледә минем белән уйнап үскән балалар: Хәмидә апа малае Хәмидуллин Рәис (иң якын дустым), безнең каршыдагы Зәйнәп апа малае Васыйл, Дәүжан апа кызлары Гөлсинә белән Бүләк.

Безнең бәрәңге бакчасы артыннан колхозның яшелчә бакчасы башлана иде. Беркөнне кич белән мин капка төбендә чирәмдә уйнап йөри идем. Офыктагы кояш, кызгылт моңсу нурларын сибеп, баеп бара. Көтү кайткан, бөтен жирдә кичке талгынлык сизелә. Шул чакта кинәт әлеге яшелчә бакчасында берәүнең моңлы итеп жырлаганы ишетелде: «Гомерем буйларына, Рәйхан, оныта алмасам, нишләрмен?» Ул тавыш шулкадәр моңлы иде ки, мин, ул әсәрләнеп, уйнаган жиремнән туктап калдым. Андый жырны беренче ишетүем иде. Ул минем бөтен күңелемне биләп алды. Менә нинди була икән ул моң! Ул хатын-кыз шул жырны жырлап бетергәнче, мин, чирәмгә утырып, аны тыңлап тордым. Менә шул көннән соң мин татар моңының үзәкләргә үтә торган сихеренә бирелә башладым, «Рәйхан» жырын тыңлаганда һәрвакыт үземнең шул беренче тапкыр ишеткән вакытымны искә төшерә торган булып киттем.

Безнең урам Кылы урамы дип атала, ул бик озын. Аның бер очы Ютазы елгасына барып чыга, икенче башы Кәрәкәшледән Урал авылына бара торган юлга барып тоташа иде. Бервакыт без Вәжһия апа белән (миңа әле биш-алты яшьләр генә булгандыр), үзебезчә «сәяхәткә чыгып», урамның шул икенче очына кадәр бардык. Анда сай гына чокырлар белән бүлгәләнеп беткән аланлык, ә аланлык артында тау башлана иде. Аланлыкта анда-санда кыр чәчәкләре күренә. Вәжһия апа шул чәчәкләрне жыйды да үзенә такыя ясап киде һәм миннән: «Ничек? Матурмы? Килешәме?» – дип сорады. Минем әле ул вакытта матурлык турында уемда да юк иде, шулай да: «Әйе, матур!» – дидем. Вәжһия апа шул вакытта ук, кыз кеше буларак, матур булу турында уйлаган икән.

Менә миңа сигез яшь. Дания апаны инәкәй Уфага, Энже апаларга, бала карарга жибәрде. Ул болай булды: Энже апаның бәләкәй баласы бар иде. Ул үзе дә, Гыйният жизни дә эштә. Ә бала карарга кеше юк. Хат аша Энже апа минем инәкәй белән сөйләшкән дә, бала карарга Дания апаны жибәрергә килешкәннәр. Шулай итеп, Дания апа Уфага, Энже апаларга китеп барды. Беркөнне кичкә таба без аны поездга озаттык; шуннан соң миңа

бик күңелсез, бөтен дөнья бушап калган кебек булды...

Кәрәкәшледә яшәгәндә, бездән сигез чакрым ераклыктагы кечкенә Алма-Ата авылындагы яшьләр безнең мәктәпкә килеп укыйлар иде. Алар ат җигеп киләләр дә, атларын безнең ишек алдында калдырып, укырга китәләр. Нигә нәкъ бездә калдыралар иде атларын? Чөнки безнең өй мәктәпкә бару юлында гына иде. Аннан соң Алма-ата яшьләре арасында безгә туган тиешле (минем инәкәйнең бертуган абыйсы Габделбәр абзыйның улы) Мөгътәбәр абый бар иде; ул, әлбәттә, сигез чакрым хәтле җирдән килгәч, безгә кермичә китми иде. Аның белән бергә башкалар да бездә тукталып, атларын безнең ишек алдында калдырып, укырга мәктәпкә китәләр иде. Дәресләр беткәч, тагын безгә кайтып, өшегән кулларын безнең мичтә җылытып, атларын җигеп, Алма-Атага кайтып китәләр иде.

Шул Алма-Атадан килеп укучылар арасыннан бигрәк тә ике кеше минем хәтеремә кереп калган. Аларның берсе – Илтөзәр абый, икенчесе – Әбүзәр абый иде. Илтөзәр абый юк кына нәрсәгә дә гаҗәпләнә, исе китә иде. Мәсәлән, безнең өйгә электр керткәндә, электр чыбыкларын, бүрәнә аша кертеп, түшәм буйлап өйнең уртасына хәтле сузганнар иде; чыбыклар асылынып тормасын өчен, аларны берничә урында ап-ак электр «кәтүкләренә» бәйләп куйганнар. Илтөзәр абый, сузылып, кулы белән шул кәтүкләрне тотып карый да, аларның шома булуларына исе китеп; «И-и, ничек шулай матур итеп ясаганнар икән боларны!» – дип соклана иде. Ә башкаларның ул кәтүкләргә исләре китми, ул шулай булырга тиеш дип карыйлар иде.

Ә Әбүзәр абый – аның әтисе Рамазан бабайны без «Бал бабай» дип йөртә идек, шуның улы – үзенең шаян булуы белән истә калган. Ә иң шаяны – безнең туганнан туган абыебыз Мөгътәбәр абый иде. Аның иң шук чагы иде ул елларда.

Шул елларда Алма-Атадан килеп укучы яшьләр «Алма-Атаның таулары» дигән җыр чыгардылар:

*Алма-Атаның таулары,*
*Өзелә камыт баулары...*

Ул болай булган: безнең Кәрәкәшледән Алма-Атага кайтканда бербер артлы өч тау менәргә кирәк. Тау менгәндә, гадәттә, егетләр арбадан төшеп, җәяү баралар; менеп җиткәч кенә арбага утыралар. Ә бер көнне, шаярыпмы шунда, өченче тауны менгәндә дә егетләр аттан төшмәгән, утырып барганнар. Ат, мескен, бөтен көченә каерылып тарта икән. Шул чакта атның камыт бавы өзелгән; егетләр аны яңадан кысып бәйли алмаганнар, шул көе генә, ничек кирәк алай авылга кайтып җиткәннәр дә колхоз дворына илтеп тапшырганнар. Безгә кергәч, шуны көлә-көлә, берберсен үртәшә-үртәшә сөйләделәр. Ә икенче көнне бу җырның шундый кушымтасы да барлыкка килде, шул кушымтасы белән дә җырладылар:

*Сине генә сөям,*
*Сине генә сагынам,*
*Сине генә килә күрәсем...*

Тиздән аңа тагын бер куплет өстәлде; аның ике генә юлы истә калган:

*Алма-Атаның сулары*
*Ерак таулардан килә...*
*Сине генә сөям,*
*Сине генә сагынам,*

*Сине генә күрәсем килә...*

Безнең урамда, безнең йортка каршы гына Рифгать абый Гыймаевлар яши иде. Әнисе – Миңсылу апа. Рифгать абый аның бердәнбер баласы иде. Әтисе сугышта үлгән. Урта мәктәпне тәмамлагач, Рифгать абый, Казанга китеп, химия-технология институтына укырга керде. Минем Казан белән кызыксынуымны искә алып, ул бераздан миңа хат белән химия-технология институты рәсеме төшерелгән открытка җибәрде. Мин моңа бик шатланган идем. Ул открытканы мин озак еллар буе саклап тоттым. Соңыннан, күп еллардан соң «Рифгать абый Мәскәүдә космонавтларны әзерләү үзәгендә эшли икән» дигән хәбәр ишетелде; әмма мин бу турыда төгәл генә белмим.

Кәрәкәшледә яшәгәндә минем дөньяны күбрәк күрәсем, әле үземә билгеле булмаган ерак илләрдә, зурзур шәһәрләрдә буласым, биек-биек тауларга менәсем, диңгезләр кичәсем килә иде. Лапас түбәсенә менеп, озак кына тирә-якны күзәтә идем. Ә аннан хәтта офыктагы таулар да күренә иде. Ерактагы ике янәшә тауны мин Ютазы таулары дип уйлый, их, шул тауларга менсәң иде, зур дөньяны күрсәң иде, дип хыяллана идем. Соңыннан гына белдем: ул таулар Акбаш авылы таулары булган икән.

Бервакыт мин үземнең классташ малай, авылның үзәк урамында (ул хәзер Мирфатыйх Зәкиев урамы дип атала) тора торган Гыймаев Әкъдәс белән дуслашып киттем. Үзем Кылы урамында торсам да, без аның белән берничә тапкыр авыл уртасындагы шоссе буйлап, киләчәк турында сөйләшеп, хыялланып йөргән идек. Шуларның берсендә Әкъдәс миңа: «Әгәр үзең язып китап чыгарсаң, акча түлиләр икән», – диде. Ул аны каян белгәндер, бу минем өчен яңалык иде. Ул вакытта мин китаплар укырга яратсам да, язучылык эше турында әле берни дә белми идем. Менә шулай итеп минем тормыш турындагы белемем әкренләп арта барды.

Еллар үтте. Без Кәрәкәшледән 1952 елда әниебезнең туган авылы Зәй-Каратайга күченеп киттек. Миңа бик ямансу иде: мин бит үземнең туган авылымнан китәм, ә тагын берәр кайчан әйләнеп кайтырмынмы-юкмы? Чыннан да, миңа туган авылыма яңадан шактый вакыттан соң гына, кунакка гына кайткалап китәргә туры килде.

Кәрәкәшледән китүебезгә инде бик күп еллар. Шушы вакыт эчендә мин чыннан да дөньяны шактый гына күрдем. Ә дөнья киң икән, иксез-чиксез икән ул!.. Менә бервакыт мин үзем бала чакта хыялланган шул Акбаш авылындагы ике янәшә тау түбәсенә дә мендем, аннан туган авылыма карап та тордым. Соңрак бик күп илләр, шәһәрләр күрдем, күп халыкларның тормышы, гореф-гадәтләре белән дә таныштым. Чит илләрдән миңа Польшаны, Чехословакияне, Германияне, Төркияне күрергә, Варшава, Прага, Берлин, Дрезден, Лейпциг, Эрфурт, Брно, Карловы Вары, Потсдам, Вроцлав, Истанбул, Әнкара, Баку, Тбилиси, тагын бик күп, бик күп шәһәравылларны күрергә, зиннәтле патша сарайларына, бөтен дөньяга мәшһүр музейларга аяк басарга насыйп булды. Туган илебезнең дә күп җирләрендә булырга туры килде миңа: Украина, Латвия, Грузия, Азербайҗан, Әрмәнстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Үзбәкстаннар буенча сәяхәт итәргә,

Карпат, Татра, Кавказда Эльбрус тавына, Башкортстанда Урал тауларына менәргә туры килде. Кара диңгездә, Баренц, Балтыйк, Каспий диңгезләрендә, Иртыш, Нева, Дим, Агыйдел, Иссык-күл суларыда коенырга насыйп булды. Һәм бу ерак юлларның барысының да башы шушы туган авылым Кәрәкәшледән башланды. Зур елгаларда, диңгезләрдә коенганчы, мин башта үзебезнең шушы ярсу агымлы Ютазы елгасында су кердем. Биек Эльбрус тауларына менгәнче, иң элек туган авылымдагы Чаукалык тавына мендем; шуннан карап, дөньяның никадәр киң, зур икәнлегенә төшендем. Шуңа күрә минем туган авылым Кәрәкәшле минем йөрәгемнең иң түренә кереп урнашты, йөрәгемнең бер кисәгенә әверелде.

## Зәй-Каратайда

Минем әнием күптән инде үзенең туган авылы Зәй-Каратайга кайтып төпләнергә уйлап яши иде. Чөнки анда аның бертуган апасы Маһикамәр абыстай бар; аннан соң, ни әйтсәң дә, туган авыл – туган авыл бит инде ул; әнинең күңеле һәрвакыт туган авылына тарта иде. Ә Кәрәкәшлегә ул килен булып төшкән. Ире, ягъни минем әти, сугышта һәлак булган; әнинең каенана-каенаталары да инде күптән вафат. Шуңа күрә аны Кәрәкәшледә тотып тора торган төп сәбәп тә юкка чыккан. Хәзер инде аңа үз туган авылына күчеп китәргә дә мөмкинлек туган. Шулай итеп, ул колхозның гомуми җыелышына, үзенә туган авылына, колхозга күчеп китәргә рөхсәт сорап, гариза язды. Менә бервакыт колхоз җыелышы була. Көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап бетергәч, колхоз правлениесенә килгән гаризаларны карауга күчәләр. Берничә гариза карала да, колхоз рәисе Җәмил Габбасов җыелышны ябык дип белдерә. Шул вакыт безнең урамдагы бригадир булып эшләүче Майкамал апа (ул бик батыр, сүзен курыкмыйча әйтә торган кеше иде): «Нигә Майпәрвазның гаризасын карамыйсыз?» – дип кычкырган. Шуннан соң гына Җәмил Габбасов минем инәкәйнең гаризасын да укырга мәҗбүр булган (аның минем әнине колхоздан җибәрәсе килмәгән. Бервакыт әни, безнең авылдан ун чакрымдагы Алма-Ата авылында яшәүче бертуган абыйсы Габделбәр абзыйдан «Мин Каратайга кайтырга уйлый идем. Кәрәкәшле (колхоз рәисе Җәмил Габбасов) мине җибәрер микән?» – дип сорагач, Габделбәр абзый: «Нишләп җибәрсен? Уйлама да. Син Кәрәкәшленең кара икмәге бит», – дип җавап биргән. Гаризада әнием үзенең туган авылына, колхозга кайтырга рөхсәт бирүләрен сорап язган була. Колхоз рәисе Җәмил Габбасов гаризаны укып бетерүгә, залдагы бөтен халык «Җибәрәбез! Җибәрәбез! Колхозга кайта бит! Туган авылына кайта!» – дип кычкырганнар. Шулай итеп, минем әни, ниһаять, туган авылына кайтырга рөхсәт алган.

Колхоз җыелышында бу мәсьәлә хәл ителгәч, без 1952 елның май башында ук күченергә әзерләнеп беттек. Чыгып китәргә әзер булсын дип, бар әйберне бәйләп, капчык-ящикларга тутырып куйдык. Бары китәргә машина гына көтеп тора башладык. Ләкин машина мәсьәләсе алай тиз генә хәл ителмәде, шуңа күрә ун көн чамасы вакытны без юлга җыенган хәлдә үткәрдек. «Менә китәбез. Менә

китәбез» дип торгач, мин мәктәпкә барудан да туктадым. Ләкин бер ун көн шулай көтеп тә, һаман да китмәгәч, моны мәктәптә дә белеп алганнар, һәм менә бер көнне миңа безнең класс җитәкчесенең «Нишләп Әнвәр дәрескә йөрми? Прогул язабыз бит. Дәрескә йөрсен!» дигән сүзләрен җиткерделәр. Шуннан соң мин берничә көн әле мәктәпкә дә бардым. Ләкин инде миңа элекке кебек үз итеп, Кәрәкәшле малае итеп түгел, ә чит итеп караучылар да табылды...

Ниһаять, бер көнне машина килде һәм без, төялеп, минем туган авылымнан чыгып киттек. Миңа ямансу иде: «Мин тагын Кәрәкәшлегә берәр кайтырмынмы икән, юкмы икән?» – дип уйладым. Ни әйтсәң дә, мин бит туган авылымнан аерылып, миңа билгеле булмаган якларга китеп бара идем. Тагын шунысы истә калды: әйберләрне машинага төягәндә, Кәүсәр абый аркылы пычкыны ашыгыбрак тоткан да, пычкы аның баш бармак белән имән бармагы арасындагы элпәне ерткан иде; абый аны кульяулыгы белән бәйләп, әйберләрне машинага ташып йөрде.

Барасы җиребезгә без Кәрәкәшледән киткән көнне генә барып җитмәдек әле: колхоз машинасы безне бары Бөгелмә шәһәренә, андагы «Колхозный двор» дигән җиргә генә китереп куйды. Без монда Зәй-Каратайдан киләчәк колхоз машинасын көтеп торырга тиеш идек. Ул машина да шул ук көнне килмәде, безгә «Колхозный двор»да ике кич кунарга туры килде. Шул вакытта мин, ерак китмичә генә, тирә-якта йөреп, шәһәр урамнары белән танышып кердем.

Әниебезнең туган авылы Зәй-Каратайга без, ниһаять, 1952 елның 20 маенда килеп җиттек. Машина безне әнинең олы апасы Маһикамәр абыстайларның капка төбенә китереп куйды. Кузовтан әйберләрне бушаттык. Аларны кертеп бетергәч, мин Маһикамәр абыстайларның капка төбендә, урамда аунап ята торган «Татар әдәбияты. 8 нче класс өчен дәреслек» дигән китапны күреп алдым һәм аның битләрен актарып карадым. Анда шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәнинең шигырьләре һәм аның биографиясе дә бар иде. Мин укып карадым: анда Утыз Имәнинең кабере Лениногорск районының Тимәш авылында икәнлеге язылган. Ә Тимәш авылының Зәй-Каратайдан ерак түгеллеген мин инде ишетеп белә идем. Бу минем өчен яңалык булды, мин: «Кара әле, шундый атаклы шагыйрьнең кабере моннан ерак түгел икән бит», – дип шатланып куйган идем. Ул вакытта әле мин урта мәктәпне бетергәч, үземнең Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керәчәгемне, аннан аспиратурада укыячагымны, фәнни җитәкчем миңа фәнни эш темасы итеп нәкъ менә Габдерәхим Утыз Имәни иҗатын өйрәнүне бирәчәген, аны ныклап өйрәнеп, 1973 елда шушы ук темага кандидатлык диссертациясе яклаячагымны, 1986 елда Татарстан китап нәшриятында аның беренче шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарачагымны башыма да китермәгән идем, билгеле. Шулай итеп минем Утыз Имәни шигырьләре белән беренче танышуым 1952 елның 20 маенда Зәй-Каратай авылында, Маһикамәр абыстайларның капка төбендә булды.

Без авылның Мәчкәрә урамында (хәзер ул Пионер урамы дип атала) бер кечкенәрәк кенә йорт сатып алып,

шунда урнаштык. Безнең йорт Мәһикамәр абыстайлар белән бер урамда, бер рәттә, алардан биш-алты йорт аша гына иде. Бу аларга барып-килеп йөрер өчен бик уңайлы булды. Урнашып беткәч, мин урамга уйнарга чыктым. Әмма урам малайлары мине бик үк дусларча кабул итмәде. Безнең йортка каршы Мәрьям апа малае Миннехан, бездән бер йорт аша гына Хөршидә апа малайлары Минсәгыйть, Минсалих, Нәфис, тагы арырак Минсылу апа малае Нәҗипләр башта минем авылның исеме Кәрәкәшледән көлеп: «Кәрәкә, Кәрәкә», – дип үртәп, үчекләп маташтылар; бары сентябрь җитеп, мәктәптә укулар башлангач кына үртәүдән туктадылар.

Зәй-Каратай авылы ул чакта нефть чыгару эшләренең үзәгендә кайный иде. Тирә-якта нефть каланчалары, скважиналар гөрләп эшләп утыра, көне-төне факеллар яна. Чыгарылган нефтьне җир өстенә салынган юан-юан торбалардан зур-зур резервуарларга кудыралар. Ул торбалар юлын туры итеп салалар: урманнарга да карап тормыйлар, аларны кисеп, юлны турыдан үткәрәләр. Шуңа күрә авыл тирәсендәге урманнар, шул юлларны салыр өчен киселеп, туп-туры ачыклыклар булып беткәннәр иде. Зәй-Каратай авылы ул чакларда тирә-якта барган шундый үзгәрешләрнең уртасында иде. Авылдагы колхозчыларның да шактые нефть чыгару эшенә күчеп, нефтьче булып киткән. Өстенә калын кожан, аягына күн итек кигән, җилкәсенә сумка аскан кешеләрнең урамнан узып йөрүе ул чакта гадәти бер күренеш иде. Болар нефть скважиналарында оператор булып эшләүчеләр, ягъни нефть кудыруны күрсәтә торган аппаратларның төзеклеген, туктаусыз эшләүләрен күзәтеп, дежур торучылар иде. Аларның күпчелеге хатын-кызлар була иде. Кайвакытта фонтан булып аткан нефть ташкынын тиз генә «авызлыклый» алмыйлар, нефть җиргә ага һәм елгаларга да килеп төшә. Ул чагында елга суы эчәргә яраклы булмый, шуңа күрә кешеләр эчәргә һәм аш пешерергә суны коедан алалар иде. Ә елгага төшкән казлар, канатлары нефтькә буялып, кап-кара булып каңгылдашып йөриләр иде.

## Яшьлек дусларым турында

Зәй-Каратайда минем иң аралашып үскән дустым – Рәхимов Закир булды. Ул Мөгаллимә апаның бердәнбер малае иде. Закирның этисе Зәки абый сугышта һәлак булган; Мөгаллимә апа башка кияүгә чыкмаган. Алар башка урамда яшәсәләр дә, бездән әллә ни ерак түгел иде, шуңа күрә без еш аралашып үстек. Без Закир белән шахмат уйнарга ярата идек. Шахматны кат-кат уйныйбыз, күбрәк ул җиңә. Ә минем җиңелүче булып каласым килми дә, без тагын уйный башлый идек.

Закирларның урамга терәлеп үк салынган йортларында, урамга караган тәрәзәләрендә бервакытта да пәрдә булмый иде. Кайчан карама – тәрәзәдән өй эчләре күренеп тора. Нигә пәрдә элмәгәндер ул Мөгаллимә апа? Үзе авыл советы депутаты, авыл активисты, үзе Мөгаллимә исемле, ә тәрәзәләре шыр ялангач: алар аша бөтен йорт эче күренеп тора. Узган-барганнар да карап үтәләрдер инде аңа? Мин моңа аптырый идем. Югыйсә авыл совет депутаты булган кеше, минемчә, башкаларга һәр яктан үрнәк

булырга тиеш иде бит. Аның йорт-каралтысы да җыелган, чиста булырга, үз-үзен дә ул башкаларга үрнәк итеп тотарга, җыйнак, чиста киенеп йөрергә тиеш кебек иде...

Ә Закир бик егетләрчә, ирләрчә булып үсте. Ул бишенче «Б» классының отряд советы председателе иде. Пионер сборлары вакытында һәр отряд командиры дружина советы рәисенә үз отрядының җыелып бетүе турында рапорт бирә. Менә шул чакларда без барыбыз да отряд советы председателе Рәхимов Закирның рапорт бирүен көтеп ала идек. Ул көчле тавыш белән үз отрядына «Отряд, равняйсь! Отряд, смирно!» дигән командалар бирә дә, нәкъ солдатларча төз адымнар белән шап-шоп атлап, дружина советы председателе каршына барып, көчле тавыш белән: «Товарищ председатель совета дружины! Отряд пятого «Б» класса для слета построен!» – дип рапорт бирә иде. Аның бу рапорты безнең әлеге пионерлар слетының бер яме булып тора иде.

Бик зур өметләр баглый идек без киләчәктә Закирга. Мәктәпне тәмамлагач, ул Казан химия-технология институтына укырга керде. Шул чакта бик тырышып инглиз телен өйрәнде. Мин аңа соклана идем. Әмма ул бик иртә вафат булды. Студент чагында ук ул Казан кызы Миңлебикәгә өйләнде. Аңардан бер кызы туды. Ә хатынының әнисе Закирны ни өчендер яратмады, нәрсәдер булса булды, Закир авырый башлады. Неврология больницасына керде, анда шактый озак ятты. Ныклап терелә алмады. Шуннан соң берничә ел яшәсә дә, ул инде элеккеге янып торган Закир түгел иде. Озакламый вафат та булды.

Без, яшьләр, мәктәпкә бик теләп йөри идек. Мәктәп безнең өчен икенче туган йорт кебек иде. Анда төрле чаралар үткәрелә, пионер тормышы гөрләп бара. Укытучыларыбыз да – бик кызыклы шәхесләр. Биология укытучысы Бастам абый, класс җитәкчесе Кәримә апа, география укытучысы Исмәгыйль абый һәм башкалар. Балалар бигрәк тә Исмәгыйль абыйдан шүрлиләр иде, чөнки ул, әгәр шаярып утырсаң, маңгаеңа бер чиртеп кенә ала; ә аның бармагы юан, бер чиртүдән маңгаең кызырып чыга инде. Менә шул Исмәгыйль абый бер елны безне җәяүле экскурсиягә алып барды. Әлмәт районында бер җирдә, колхоз кырында 1930 елларда, җир сөреп йөргәндә бер тракторист машинасы белән җиргә убылып төшеп киткән; шунда тирән чокыр барлыкка килгән. Аны «карст күренеше» дип аңлаталар икән. Табигатьнең шул сирәк була торган күренешен карарга безне җәяүле экскурсиягә алып барды Исмәгыйль абый. Басу уртасында бик тирән бер зур чокыр хасил булган. Бер-икебез курка-курка гына шул чокыр кырыена килеп аска карадык: анда, тирән чокырда елга булып су агып ята иде. Шулай итеп без бервакыт табигатьтә шактый сирәк була торган гаҗәп күренеш белән танышып кайттык.

Яз көне, гадәттә Җиңү бәйрәме көнендә, без, башлангыч класс балалары өчен, авылдагы демонстрациядән соң бергәләп тауга менеп урап кайту оештырыла иде. Мин ул сәяхәтне бик ярата идем. Безнең авылның төньягында ике яруслы биек тау бар; башта тауның беренче катына, аннан уратыбрак (турыдан менеп булмый) икенче тау түбәсенә менә идек. Ул

тау башыннан тирә-якка бик еракларга киң горизонт ачыла. Тау өстенә менеп баскач, шатлыктан: «Ур-ра! Мин тау башында!» – дип кычкырасың. Андый тауга менүләрне ел саен диярлек укытучылар оештыра иде. Ә бер елны нишләптер укытучылар, авылның үзәк урамыннан кызыл флаглар күтәреп йөргәннән соң, өйләренә кайтып киттеләр; без, алты-җиде малай, тауга үзебез генә мендек. Ул тауга менүне оештыручыларның берсе мин булдым.

Яшүсмер вакытымда мин малайлар белән сугышып үсмәдем. Әниемнең йогынтысы булгандыр (ул, авылның остабикәсе, мине тыйнак итеп тәрбияләде), мин үземнең бер генә дәныклап сугышканымны хәтерләмим. Ә шулай да бер мәртәбә көч сынашу булып алды. Ул болай булды.

Мин сигезенче класста укый идем. Мәктәптән кайтканда без бераз үзәк урамнан барабыз да безнең «Пионер» урамына борылабыз. Безнең урамның аргы башында ук аркылы Дунай урамы бар. Шул урамнан мәктәпкә килеп укучы ике малай бар иде; берсе – олырагы алтынчы класста, икенчесе дүртенчедә укый. Мәктәпкә барганда да, кайтканда да алар безнең өй турыннан узып китәләр. Шулай бервакыт, мәктәптән кайтканда, боларның зуррагы, ярпачланып китеп, миңа бәйләнмәкче була башлады. Мин, әлбәттә, каршы тордым, бирмәдем. Көрмәкләшеп киттек. Ничектер шулай килеп чыкты, мин аны аркасыннан уратып алдым да, үземнең култык астына кыстырдым; ул берни эшли алмады. Ә икенчесе, миңа һөҗүм итәргә азапланып, минем тирәмдә бөтерелеп йөри. Ләкин ул да берни дә эшли алмады. Шулай мин, олысын култык астына кыстырган килеш, шактый гына алып бардым. Аннан соң гына ычкындырдым. Алар мине үрти торган сүзләр кычкыра-кычкыра китеп бардылар. Шуннан соң алар мәктәптән кайткан вакытларда миңа башка бәйләнмәделәр.

Бервакыт, мин сигезенчедә укый идем шикелле, Кәүсәр абый миңа Казанның бер урамын фотога төшереп алып кайтты. Ике фото иде ул. Анда шәһәрнең гадәти бер урамы, ә урамда бер-ике кеше йөри. Мин аларны бик яратып карадым. Ул кешеләр миңа бик бәхетлеләрдер кебек тоелды, чөнки алар Казанда яшиләр бит. Ә Казан минем өчен ул вакытта барлык шәһәрләрдән дә мәшһүррәк, матуррак һәм кадерлерәк кебек тоела иде.

Зәй-Каратайда мәктәптә укыган чакта бер елны (1958, йә 1959 ел булгандыр, төгәл хәтерләмим) укучылар белән очрашырга Казаннан шагыйрь Илдар Юзеев килде. Без, өлкән класс укучылары, актлар залына кереп утырдык. Ул шунда үзенең мәхәббәт турындагы шигырьләрен укыды. Бу – аның «Таныш моңнар» поэмасының бик популяр чагы иде: якшәмбе көннәрендә еш кына Казан радиосыннан шушы поэманы, Зөфәр һәм Резидә җырлары белән, музыкаль тапшыру итеп бирәләр иде. Бу кичәдә Илдар Юзеев үзенең шигырьләрен укыгач, аңарга күп кенә сораулар бирделәр; укучылар белән шагыйрь арасында эчкерсез сөйләшү барлыкка килде. Кичә тәмамланып, Илдар Юзеев чыгып китәр алдыннан мин аңа үземнең бер-ике шигыремне күрсәттем. Ул укып карады да, мине хуплап: «Язгыгыз, язгыгыз! Күбрәк язгыгыз!» – дип, киңәшен бирде. Бу очрашудан соң мин: «Илдар Юзеев-

ның үзе белән сөйләштем бит әле!» – дип, бик озак шатланып йөргән идем.

Мәктәптә без бик тырышып укыдык. Безнең класста өч отличник бар, шуларның берсе мин идем. Тагын берсе – Венера Сәмәрханова, авылның активисты, берничә ел авыл советы рәисе булып торган Сәмәрханов Гариф кызы, икенчесе – безнең авылдан алты-җиде чакрымдагы Чәшеле хуторы дигән авылдан килеп укучы Нәкыя исемле кыз. Ул бик башлы, бик тиз эләктереп ала, һәм без аңа соклана идек; ә кайберләребез хәтта аңардан көнләшә дә иде. Һәр уку елын ул «Мактау кәгазе» белән тәмамлады. Бервакыт, мәктәпне бетереп, инде кырык еллар узгач, мин очраклы рәвештә Нәкыяне очраттым. Хәлләрне белештек: аның гаилә тормышы барып чыкмаган; ире эчә торган кеше булган, тату яшәмәгәннәр; ике баласының берсе (кызы) үлгән; ә улы, әтисе йогынтысына бирелеп, тәртипсез булып үскән. Шундый авырлыкларны кичерү аркасында Нәкыя дингә бирелгән, үз авылларында хәзер остабикә булып йөри икән.

Ә Сәмәрханова Венера, Бөгелмәдә педучилище тәмамлап, бер авылда мәктәптә укыта икән.

Унынчы классны тәмамлагач, без, ике унынчы класс укучылары бергә, Казанга экскурсиягә барган идек. Колхоз безгә машина бирде, һәм без, йөк машинасының әрҗәсенә төялеп, Казанга барып, Ирек мәйданы, Тукай, Пушкин һәйкәлләре һәм башка истәлекле урыннар белән танышып кайттык. Шунысы исемдә калган: кайтканда без, кызлар-малайлар барыбыз да, үзебез белгән җырларны кычкырып җырлап кайттык. Бу – безнең иң романтик, яшәргә ашкынып торган яшь чагыбыз. Ул минутларны мин әле дә бик сагынып искә алам.

Минем әнием Маһипәрвәз тирәякта данлыклы остабикә иде. Ул Әлмәт районы Камы-Исмәгыйль авылындагы кызлар мәдрәсәсендә укыган, аны тәмамлап, шәһадәтнамә, ягъни диплом алган белемле кеше иде. Авылдагы мәҗлесләрдә Коръән һәм мөнәҗәтләр укуны гел аңа тапшыралар иде, чөнки аның тавышы бик моңлы һәм ягымлы иде. Әни мине тыйнак итеп тәрбияләде, кешелекле булырга, эреләнмәскә-мактанмаска өйрәтте. Шунлыктан тыйнаклык минем каныма, рухыма балачактан ук сеңеп калды. Яшьлегем чәчәк аткан чакта, егет булып йөргән чакларда да мин беркем алдында да (хәтта кызлар алдында да!) һаваланмый, мактанмый идем. «Менә мин нинди!» – дип, үземә игътибар иттереп, үземне алга чыгарып сөйләгәнем булмады. Шуңа күрә булса кирәк, мин мактанчык, «ярпач» кешеләрне яратмыйм. Ә андый мактанчыклар без мәктәптә укыганда да, аннан соң да минем тормыш юлымда шактый очраштырды әле. Хәтта язучылар арасында да (нигә яшереп торырга?!) андыйлар бар әле. Аларның бу сыйфаты әсәрләрен укыганда, анализлаганда да искә килеп төшә һәм алган тәэсир ничектер тоныкланып кала иде.

Урта мәктәпне бетергәч, мин, авылда беренче буларак, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кердем. Безнең авылдан Казандагы төрле институтларга укырга керүчеләр булса да, әле моңа кадәр университетка укырга кергән бер кеше дә юк иде.

## Кәүсәр абыем турында

Мин бәләкәй чагында Кәүсәр абый велосипедта мине үз алдына, велосипедның алдагы тимеренә утыртып йөри иде. Мине шунысы гаҗәпләндерә иде: ул аяклары белән педальне дә әйләндерә, шул ук вакытта велосипедның алдагы тәгәрмәче алдында чокыр-фәлән юкмы – шуны да күзәтеп, тигез юлны сайлап, тәгәрмәчне шул тигез җиргә генә бастырып алып бара иде.

Күп еллардан соң, инде мин фән докторы, профессор дәрәҗәсе алгач, бервакыт Зәй-Каратай мәктәбендә укучылар белән очрашу булды. Кичәнең рәсми өлешеннән соң, чәй янында сөйләшеп утырганда, пионервожатый Халидә апа: «Әнвәрнең абыйсы Кәүсәр бар иде, бик шәп кеше иде!» дип әйтеп куйды. Чыннан да, минем абый бик максатчан, көчле рухлы, үз-үзенә ышанган, шәп кеше иде. Аның кулыннан килмәгән бер эш тә юк иде. Бөтен нәрсәне үзе, үз кулы белән эшли иде. Ул хәтта Зәй-Каратайдагы безнең йортны да ул үзе салды: өмә итеп буратты, өмә итеп йортны күтәртте. Кәүсәр абыйны мин «Бәя бирелмәгән гений» – дип атап йөртә идем. Чөнки үз вакытында аның кешелек сыйфатларына, осталыгына, тырышлыгына, ярдәмчел булуына игътибар итүче, тиешле бәя бирүче кеше булмады.

Кайвакыт мин Кәүсәр абыйны җизни Марсель (Вәҗһия апаның ире) белән чагыштырып карыйм. Миңа, мәсәлән, бервакытны Әлмәттә, Марсель җизни белән икәү генә, аның машинасында шәһәр буйлап йөрергә туры килде. Руль артында – җизни. Вәт чаптырды ул машинаны! Дүртенчеме, бишенчеме тизлеккә куйды да, бернигә карамыйча, турыдан җилдертте генә! Аның өчен чокыр-чакыр да, берни дә юк иде. Ну калтыранды инде машина! Ничек таралып китмәгәндер. Бер дә жәлләмәде, саклап тотмады ул машинасын. Ә минем Кәүсәр абый бервакытта да алай эшләмәс иде; ул һәр нәрсәнең кадерен, бәясен белеп, саклап, ватмаска-җимермәскә тырышып яшәде.

## Алабуга чоры

Мин Казаннан Алабугага 1978 елның ноябрь ахырында күченеп килдем. Студентларның тулай торагыннан үземә бер бүлмә бирделәр. Дүртенче катта иде ул бүлмә. Мин, шунда яшәп, Алабуга пединститутында «Борынгы татар әдәбияты», «XIX гасыр татар әдәбияты», «Әдәбият теориясе», «Фәнни атеизм», «Татар балалар әдәбияты» дигән предметларны, ә Алабуга пединститутының Чаллыдагы филиалында ике факультетта (педфакта һәм дошфакта) «Татар балалар әдәбияты» дигән предметны укыта башладым. Вузларда укыту өчен «Татар балалар әдәбияты» предметы әле эшләнмәгән иде, бары Фатыйма Ибраһимованың «Заман белән бергә» (Казан, 1971) китабы гына бар иде. Шунлыктан бу предметны, аның һәр лекциясен, һәр практик дәресен тулысынча үземә эшләргә, үземә әзерләргә туры килде. Тулай торакка үземнең китапханәмне дә алып килдем. Аны урнаштырырга шкафым юк иде; китапларны, кирәклесен тиз табарлык булсын өчен, идәнгә рәт-рәт итеп тезеп куйдым. Шул вакытта минем идәнгә тезеп куйган китапларны

Разил Вәлиев кереп күреп чыкты (ул вакытта Разил Вәлиев Чаллы Язучылар оешмасының рәисе иде). Ә инде Чаллыда да укыта башлагач, миңа квартирны да Чаллыдан бирделәр. Шулай итеп, мин Чаллы кешесе булып киттем.

Чаллыда мин педагогия институтында укыттым. Фән буенча да кайбер уңышларга ирештем кебек, үземә калса... 1973 елда Казанда «Габдерәхим Утыз Имәнинең иҗат мирасы һәм аның поэзиясендә дөньяви мотивлар» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклаган идем, ә менә шагыйрьнең әсәрләрен аерым китап итеп чыгару өчен әзерләмәгән идем әле – шуны әзерләп, Татарстан китап нәшриятына илтеп бирдем. Китап 1986 елда басылып та чыкты. Ләкин минем бу фәнни хезмәтләрем Казан масштабы белән чагыштырганда бик үк мактанырлык булмады. Чөнки монда фәнни эш акрын бара; Казанда булсам, мин аларны тизрәк һәм күбрәк эшләгән булыр идем.

Докторлык диссертациясенең темасын ачыкладым, аңа материаллар җыя башладым. Ләкин провинциядә яшәп, борынгы әдәбият өлкәсендә докторлык диссертациясе язу өчен кирәк булган һәм җитәрлек материалны туплауны күз алдына да китереп булмый. Бу мөмкин эш түгел, шуңа күрә зур фән үзәкләренә командировкаларга барырга кирәк иде. Чаллы китапханәләрендә хәтта татарча 1910–1917 елларда чыккан газета-журналлар да юк; ә инде шул елларда чыккан фәнни китапларны яки кульъязма материалларны табу турында әйтеп тә торасы юк. Шуңа күрә 1940 елларга кадәр чыккан татарча газета-журналлар кирәк булса, аларны уку өчен Казанга барырга мәҗбүр булдым. «Казаннан башка җирдә дә тормыш бар бит әле» дигән фикер белән Чаллыга килеп урнашканнан соң, мин әнә шундый хәлгә тарыдым...

Беркадәр әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә башладым. Дөрес, балачактан ук мин вакыты-вакыты белән шигырьләр язгалый идем инде. Ләкин ул чакларда миңа язучылык хезмәте буй җитмәслек зур, бөек, серле бер нәрсә кебек тоела иде. Тормышыма беренче мәхәббәт килеп кергәч, минем иҗатыма да мәхәббәт темасы килеп керде. Мәхәббәт турында шигырьләр язсам да, мин бөтен күңелем белән язучылык эшенә бирелеп китә алмадым; бәлки, үз-үземә ышанычым көчле булмагандыр. Шунлыктан булса кирәк, мин шигырьләремне аерым китап итеп чыгарырга һаман батырчылык итми йөрдем (әлбәттә, монда минем артык тыйнаклыгым, кыюсызлыгым да зур роль уйнады). Югыйсә минем белән бер группада укыган Равил Фәйзуллин, Шамил Маннапов, Фарсель Зыятдиновлар, соңрак Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимовлар, житди рәвештә иҗат белән шөгыльләнеп, күренекле шагыйрьләр булып танылдылар. Ә мин һаман иҗат белән ныклап шөгыльләнеп китә алмадым. Бөтен тырышлыгымны фәнгә бирдем.

Һәм, ниһаять, 2001 елда докторлык диссертациясе яклагач кына, мин әдәби иҗатка беркадәр житдирәк итеп карый башладым. Үземнең моңа кадәр язган шигырьләремне бер җыентыкка туплап, 2006 елда «Кем иден син?» дигән китап чыгардым.